ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«13» декабрь 2021 ел № 409

Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 25 мартындагы 80 номерлы карары белән расланган «2021-2022 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Гамәлдәге законнарны хокукый мониторинглау нәтиҗәләре буенча муниципаль норматив хокукый актны тәңгәлләштерүгә бәйле рәвештә, шулай ук “Террорчылыкка каршы торуны тәэмин итү өчен җиһазлар сатып алуга бәйле чыгымнарны тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансферлар бирү турында” Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты арасындагы Килешү нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 25 мартындагы 80 номерлы карары белән расланган «2021-2022 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Программаның паспортында «Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td rowspan="3">Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары:</td><td colspan="3">Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан программаны финанслауның гомуми күләме:</td></tr>
<tr><td>ел</td><td>җирле бюджет</td><td>республика бюджеты</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>207.7 мең сум.</td><td>122.5 мең сум (спорт инвентаре);<br>331.4 мең сум (хоккей буенча программаларны тормышка ашыруга)<br>750.7 мең сум (террорчылыкка каршы яклануны тәэмин итү өчен</td></tr>
</table>

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | җиһазлар сатып алуга бәйле чыгымнарны тәэмин итү) |
| | 2022 | 200 мең сум | 124.5 мең сум (спорт инвентаре);<br>350 мең сум (хоккей буенча программаларны тормышка ашыруга) |
| | | | |
| | Барлыгы | 407.6 мең сум | 1679.1 мең сум. |

1.2 «2021-2022 елларга Әгерҗе муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү чаралары» бүлегенең 5 нче бүлекчәсе таблицасын түбәндәге эчтәлекле 5.7 юл белән тулыландырырга:

| № | Чаралар эчтәлеге | Башкару срогы | Үтәү өчен җаваплылар | Финанслау күләме (сум.) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2021 | | 2022 |
| 5.7 | Спорт объектларының террорчылыктан сакланышын тәэмин итү өчен җиһазлар сатып алуга бәйле чыгымнарны тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе нигезендә бюджетара трансфертлар | 2021-2022 | МБУ «Спорт мәктәбе»; МБУ СОК «Олимп»» | 7.6 (җирле бюджет) | 750.7 (республика бюджеты) | - |

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**